**Татарстан Республикасы**
**Әлки муниципаль районы**
**Базарлы Матак авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

2019 елның 26 ноябре 132№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге территориясендә 2019 елның 24 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы һәм җирле референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре, референдум нәтиҗәләре турында 715, 716, 717, 718, 719, 733, 758 номерлы сайлау комитеты участокларының беркетмәсе (Татарстан Республикасы Базарлы Матак авыл җирлеге МБСК) нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Базарлы - Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумы үткәрелгән, ә референдум нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Җирле референдумда түбәндәге мәсьәләләр буенча карарлар кабул ителгән дип санарга:

"2020 елда Базарлы Матак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, 80 яшькә җиткән пенсионерлар, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 540 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

-урамнарны яктырту һәм техник хезмәт күрсәтү, эш өчен түләү, электр энергиясе өчен түләү, материал сатып алу-160 сум;

-су белән тәэмин итү системасын һәм суэтем башняларын ремонтлау, суэтем башнялары территорияләрен төзекләндерү, су анализлау буенча хезмәтләр өчен түләү, материал сатып алу-110 сум;

- паркларны реконструкцияләү, төзекләндерү һәм карап тоту (инвентарь һәм материал сатып алу, белгечләр эше өчен түләү, яктыртуны тәэмин итү)-50 сум;

- зиратларны төзекләндерү (коймалау, җир эшләре, агач кисү, инвентарь һәм материал сатып алу)-50 сум;

- юл челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, җәяүлеләр юлларын билгеләү, материал сатып алу, эш өчен түләү-120 сум;

-чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, белгечләр эше өчен түләү-50 сум.

тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегендә 4764 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 3326, бу - 69 % тәшкил итә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге референдумының тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.

4. Үзара салым акчаларын Базарлы Матак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, 80 яшькә җиткән пенсионерлар, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 540 сум күләмендә әлеге карарны халыкка җиткергәннән соң 12 ай эчендә барлык гражданнар түләргә тиеш.

Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Базарлы Матак
авыл җирлеге башлыгы: А. Ф. Никошин